Буа ветеринария техникумында “Нәүрүз гүзәле - 2021” дигән музыкаль кичә туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан уздырылды. Техникумның иң уңган, булган, матур, сылу биш кызы бәйгедә, осталыкта һәм уңганлыкта, җитезлеклектә, тапкырлыкта көч сынашты.

Көтелгән минутларны якынлаштырып, берничә номинацияне үз эченә алган бәйгенең башлануын игълан иткәч, кызлар төз итеп атлап, бер-бер артлы зал уртасына уздылар. Кфызларның йөзләреннән нур бөркелә, шул ук вакытта дулкынлану мизгелләре дә чагыла.

Бәйгенең "Әйдә кызлар, таныш булыйк" номинациясендә кызлар үзләре белән таныштырып үттеләр. "Гыйлем - кояш, акыл - канат" номинациясендә һәркемгә бишәр сорау бирелде, ә алар һич кенә дә югалып калмыйча, сорауларга җавап бирделәр. Бәйге барышында кул эше осталыгы, прическа ясау номинацияләрен дә уңышлы үттеләр.

"Тәрбиядән яраладыр тәрбия" номинациясе бәйрәмгә рухи җанлылык өстәп, залга ялкын һәм милли көйләрнең тылсымлы бер ямен өстәде. Катнашучылар татар телен белүләрен, шулай ук куелган сынауларга иҗади якын килеп, барлык биремнәрне тырышып үтәделәр: татарча җыр башкардылар, очып-очып биеделәр, бүгенге көндә онытылып барган гореф-гадәтләребезне күрсәттеләр.

Дулкынлану һәм бер мәлгә читенсенеп, югалып калу мизгелләре булгаласа да, жюриның сынаулы карашлары төбәлсә дә, кызлар һич кенә дә бирешмәделәр, ә киресенчә, тагын да яхшырак булсын дигәндәй, бар сәләтләрен эшкә җиктеләр, сер бирмәделәр.

Шакирова Азалия һәр номерны бөтен нечкәлекләренә кадәр туры китереп үтәп, "Нәүрүз гүзәле" исеменә лаек булды.

Вәлиева Илзирә һәр яктан талантлы булуы белән залдагыларны сокландырды һәм "Нәүрүз сылуы" һәм онлайн сайлау нәтиҗәләре буенча "онлайн Нәүрүз гүзәле" исемен алды.

Гисматуллина Илүзә тапкыр, сөйкемле, җыр-биюгә осталыгы белән дан тотып "Нәүрүз чибәре" дип танылды.

Хакимова Әнисә тәвәккәл, кул эшенең остасы булуы белән күңелләргә хуш килде, шуңа күрә ул "Нәүрүз уңганы" номинациясе җиңүчесе булды.

Фахретдинова Динара үз-үзен тотышы, матурлыгы белән залдагыларны сокландырды һәм "Нәүрүз матуры" исемен алды. Кызларыбызга киләчәктә зурдан зур уңышлар теләп калабыз!


ВЕТЕРИНАРНЫЙ
ТЕХНИКУМ


ВЕТЕРИНАРНЫЙ
ТЕХНИКУМ


ТЕХНИКУМ


ВЕТЕРИНАРНЫЙ
ТЕХНИКУМ






ВЕТЕРИНАРНЫЙ
ТЕХНИКУМ

